| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**26.10.2020** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2084** |

2021 елга Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 21 декабрендәге 1879 номерлы карары белән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елга Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрдә тәрбияләнүчеләрне тотуга кушымта итеп бирелгән чыгымнарны расларга(1нче кушымта).

2. «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ түбәндәгеләр тарафыннан расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә:

- «2021 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында Һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2020 елның 26 сентябрендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;

- әлеге карарның 1 пункты.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4.Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (htpp:/pravotatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск

муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Мәгариф идарәсе начальнигы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта
26.10.2020 № 2084

**Зеленодольск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашуы | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елына сумнарда |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 92851 |
| | авыл җирлеге | 94213 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 139227 |
| | авыл җирлеге | 143701 |